ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.08.2026 г.Лениногорск № 609

Лениногорск муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 15 өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәреш кертү турында» 2025 елның 29 сентябрендәге 776 номерлы карары белән, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 3 февралендәге 74 номерлы «Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

2.Лениногорск муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru)

«Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләгәндә әлеге карар белән раслана торган тәртипкә таянырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И.Г. Шәмәрданов

Р.Р. Галимов
5-01-61